Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Трой-Урай авыл җирлеге Советы

КАРАР № 6

Трой-Урай авылы 7 декабрь, 2021 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге Советының 2014 елның 6 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, 2021 елның 7 июлендәге “Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”305-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Трой-Урай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге Советының 2014 елның 6 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 12 номерлы карарына (2014 елның 11 ноябрендәге 15 номерлы, 2015 елның 25 маендагы 12 номерлы, 2017 елның 12 июлендәге 7 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 10 номерлы, 2020 елның 4 февралендәге 2 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында “, шулай ук күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен аталган җир кишәрлекләре” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның салым чорындагы җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авылы, Мәктәп урамы, 13 нче йорт,Кама –буе урамы,9 йорт;Гремячка авылы, Александров урамы 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Трой-Урай авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Сафин